Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№7 (100)

13 март 2014 ел



# Татарстанның иң зур байлыгы

Мартның күңелләргә матурлык, сафлык, дәрт-дәрман өсти торган гүзәл бер көнендә Казан студентлары һәм чит илләрдән килгән студентлар «Идел» Яшьләр үзәгенә, «Тарстанның мәдәни мозаикасы» фестиваленә җыелды. Аларның төп максатлары Татарстан Республикасы яшьләре арасында мәдәниятара диалог атмосферасын үстерү һәм саклау.

## Вакыйгалар эзеннән

**7-9 МАРТ** көннәрендә университетыбызның **АКТИВЛАР МӘКТӘБЕ УЗДЫРЫЛДЫ**. Аны КФУның Яшьләр сәясәте департаменты һәм Иҗтимагый студент оешмалары һәм берләшмәләренең координация советы оештырды. «Байтик» балалар савыктыргыч лагеренда Казан федераль һәм республикабызның башка университет студентлары өчен креатив-интеллектуаль уеннар, тренинг һәм мастер-класслар оештырылды. Бу елда программа күбрәк командаларны оештыру һәм социаль проектлаштыру юнәлешләренә багышланган иде.

• • • •

**7 МАРТ** көнне British Petroleum (BP) компаниясенең стипендия программасы җиңүчеләренә һәм фәнни коллективларга **ГРАНТ ТАНЫКЛЫКЛАРЫН ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ** булды. Стипендиягә университетыбызның 15 студенты һәм аспиранты, 5 фәнни коллективы – фәнни-тикшеренү проектларына булышлык программасы җиңүчеләре лаек булды.

• • • •

**7 МАРТТА** КФУның Яр **ЧАЛЛЫ ИНСТИТУТЫ** делегациясе завод җитәкчелеге чакыруы буенча **«ЕЛАЗ» АВТОМОБИЛЬ ЗАВОДЫНА БАРДЫ**. Очрашу барышында исәпләү программалары белән идарә ителә торган станокларда эшләүче белгечләрне яңадан әзерләү мәсьәләләре турында сөйләштеләр. Мондый хезмәттәшлек КФУның Инжиниринг үзәге ярдәмендә тормышка ашыралачак.

• • • •

**11 МАРТ** көнне КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** һәм **КӨНЬЯК, ТӨНЬЯК АРКТИК, ТӨНЬЯК КАВКАЗ** федераль университеты һәм **САНКТ-ПЕТЕРБУРГ** дәүләт икътисад университетлары **РЕКТОРЛАРЫ** Кырымда уртак **МАТБУГАТ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮТКӘРДЕ**. Уку йортлары җитәкчеләре җирле халыкка белем бирү программалары турында сөйләделәр.

• • • •

Мәскәүдәге Дәүләт тарих музеенда «Россия тарихында музейлар һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлегендә сәүдәгәрлекнең әһәмиятен интерпретацияләү» дип аталган семинар үз эшен башлап җибәрде. Пленар утырышта профессор **ИНГА МАСЛОВА** һәм доцент **ИРИНА КРАПОТКИН**а КФУның Алабуга институтының фәнни, белем бирү һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегендә сәүдәгәр династияләренең роле турында доклад белән чыгыш ясадылар. Алабуга институтының төбәк тарихы тикшеренүләре лабораториясе әзерләгән **«КУПЕЧЕСКОЕ СТРОИТЕЛЬСТВО В ЕЛАБУГЕ»** дип исемләнгән фәнни-популяр фильм да катнашучыларда зур кызыксыну уятты.

• • • •

Шул ук көнне Экология һәм география институтында **«УРМАН ЭКОСИСТЕМАЛАРЫН МОДЕЛЬЛӘШТЕРҮ»** дип исемләнгән лекцияләр циклы башланды. Аны бу өлкәдә дөнья белгечләре арасында аерым урын алып торучы Александр Комаров укыды.

• • • •

**11 МАРТТА КФУ**ның **АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ** Максим Танк исемендәге **БЕЛОРУССИЯ** дәүләт педагогика университетына рәсми **ВИЗИТЫН** башлап җибәрде. Визитның төп максаты – уку йортлары арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул кую.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Мөнбәр

Кечкенәдән «Кем буласың килә?» дигән сорауга, «Укытучы», – дип җавап бирә идем. Теләк-хыяллар әкренләп чынга аша. Университет укыту сәләтен барлау, үстерү мөмкинлекләрен тудырып кына тора. Шундый мөмкинлекләрнең берсе – педагогик осталыкны үстерү буенча VI Бөтенрәсәй студентлар бәйгесе «Ана теле – 2014».

# Куйган максатка таба!

**Айгөл АБДРАХМАНОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты



Әлеге бәйге берничә ел дәвамында уздырылып килә. Быел ул 4-6 март көннәрендә Башкортстан республикасының башкаласы Уфа шәһәрендә М.Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогика университетында узды. **«Ана теле – 2014»** бәйгесе танылган халык язучысы Суфиян Шәмсетдин улы Поварисов шәхесенә багышланды.

Бәйге берничә баскычтан торды. Икенче турга йөзгә якын теләк белдергәннәр арасыннан 12 студент сайлап алынды. КФУ даның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай ис. филология һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 4 курс студентлары – Лилия Якупова, Рөстәм Шәмсетдинов һәм Айгөл Абдрахманова яклады.

Һәр этап үзенчә кызыклы һәм «куркыныч» иде. Таныш булмаган аудитория каршында чыгыш ясау бик дулкынландыра. Ләкин укытучы булырга теләгән кеше бу хисне дә җиңеп чыгарга тиеш. Бар көчебезне җыеп, югары уку йортыбыз һәм үзебез белән таныштырдык. Киләсе этапта казыйларга алдан әзерләп килгән педагогик эсселарыбызны тәкъдим иттек. Һәр катнашучы әлеге бәйгегә үзенчә якын килгән. Берәүләр укытучы белән укучы арасындагы мөнәсәбәтләргә басым ясаса, икенчеләр укыту методикасындагы проблемаларга игътибар итүне кирәк тапкан. Жюри әгъзалары һәр катнашучының эшен югары бәяләде һәм һәр конкурсантның проблема итеп алган мәсьәләсенә карата үз фикере булуын ассызыклады. «Ана теле – 2014» бәйгесенең иҗади бирем өлеше – иң күңелле мизгелләрнең берсе, дисәм, һич тә ялгышмам. 12 генә студент катнашуга карамастан, университет диварларында сәгатькә якын милли җырлар, милли моңнар һәм бию көйләре яңгырап торды.

Укытучы һәр яктан камил булырга тиеш диләр. Соңгы этапта конкурсантларның шушы сыйфатлары тикшерелде дә инде. Уфа каласының 84 номерлы мәктәбе безне кочагын җәеп каршы алды. Укучылар да, мөгаллимнәр дә укытучы булу теләге белән янып йөрүче 12 студентка көч биреп, яхшы сүз белән җанны җылытып тордылар. Бер-беребезгә ярдәм итүне дә онытмадык, әлбәттә. Һәрберебез, алдан сайлаган сыйныфларга кереп, татар теле һәм әдәбиятыннан дәрес биреп чыктык. Дәресләрне казыйлар гына түгел, мәктәп укытучылары да карап, бәяләп утырдылар.

Бәйгенең барлык этаплары да артта калды. Алда иң дулкынландыргыч мизгел – җиңүчеләрне бүләкләү. Шулай итеп, **Р.Шәмсетдинов** (фәнни җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, доцент Ә.Р.Мотыйгуллина) «Иң үзенчәлекле дәрес» номинациясендә бүләкләнде. **А.Абдрахманова** (фәнни җитәкчесе – филология фәннәре кандидаты, доцент М.М.Шәкурова) икенче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнде... лаек булды. **Л.Якупова** (фәнни җитәкчесе – педагогика фәннәре докторы, профессор Ф.Ф.Харисов) иң зур бүләк – Гран-прига ия булды.

Шуның белән «Ана теле – 2014» бәйгесе ахырына якынлашты. Ләкин күңелләрдә һәр мизгел якты истәлек булып уелып калды. Бәйгедә катнашкан һәр студент киләчәктә укытучы булачагына чын күңеленнән ышана һәм өметләнә!

• Заман таләбе



Влад Михневский фотосы

# Яңа адым ясалды

**Алинә САДЫЙКОВА**

11 март көнне университетыбыз тагын бер структурага баеды: Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында DAAD мәгълүмати үзәген ачу тантанасы булды.

DAAD (академик алмашуның Германия оешмасы) – студентлар һәм галимнәр алмашы ярдәмендә халыкара академик мөнәсәбәтләр, фәнни кооперацияләр үсешенә булышлык итә һәм Германиянең барлык югары уку йортларын берләштерә торган үзидарә оешма. DAAD Германиянең мәгълүмати сәясәтен һәм тышкы мәдәниятне гамәлгә ашыру буенча арадаш оешма булып исәпләнә, аның 14 чит ил вәкиллеге һәм 50дән артык мәгълүмати үзәкләре бар.

Әлеге үзәкнең эшчәнлеге күпкырлы: уку йортларында мәгълүмати чаралар үткәрә, төрле белем бирү күргәзмәләрендә катнаша, Германиядә белем алу, фәнни стажировка һәм андагы түләүле уку буенча консультация бирә. Германиядәге мәгариф һәм фәнни юнәлешләр, стипендиаль программалар, шул исәптән ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә «Алгарыш» төбәк проектлары («Николай Завойский» һәм «Евгений Завойский» стипендиаль программалары) гамәлгә ашыруда, университетларга немец партнерлары белән уртак эшчәнлектә ярдәм итә, А.Н.Туполев ис. Казан техник фәнни-тикшеренү институты каршындагы GRIAT (Германия-Россия гамәли технологияләр институты) академик программалары турында хәбәр итә һ.б.

Үзәк ачылышында университет җитәкчелеге, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты вәкилләре һәм DAAD үзәге хезмәткәрләре, республикабызның башка югары уку йорты җитәкчеләре, студентлар катнашты.

DAADның «Төньяк» бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре докторы Анетте Пиппер исә үзәк турында тулырак мәгълүмат бирде һәм Татарстан белән хезмәттәшлеккә шат булуын әйтте: «Татарстан – мәгариф һәм фән буенча әйдәп бара торган төбәкләрнең берсе. Шуңа күрә үзәгебезне монда ачарга булдык, шуның нәтиҗәсендә республикагыз белән элемтәләр тагын да ныгыр дип уйлыйбыз».

Казандагы DAAD мәгълүмати үзәгенең директоры итеп Тило Цинеккер сайланды. Ул үзенең сәламләү сүзендә, студентларга мөрәҗәгать итеп: «Безнең үзәк, бу бина бик матур, әмма ул әлегә буш. Шуңа күрә мин сезне аңа җан кертергә, безнең белән эшләргә чакырам!» – диде. Тәкъдим ителгән мөмкинлектән файдаланырга ашыгыгыз!

• Ерактагы якын кардәшләр

# Татарстанның иң зур байлыгы

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**Башы 1нче биттә.**

Татарстанның төп үзенчәлеге нидә? Җиле дә вакытында исеп, яңгыры да вакытында явудамы, әллә бетмәс-төкәнмәс булып тоелган җир асты байлыклары булудамы? Анысы да бардыр. Әмма аны Рәсәйнең башка төбәкләреннән аерып тора торган төп күрсәткеч – күпмилләтлелек. Бүген республикабызда яшәүче халыкларны аерым атап торуның кирәге юк. Алар бит барыбер икенче йортлары итеп Татарстанны саный. Татар халкының толерантлы менталитетын истә тотсаң, моңа тагын бер кат инанасың. Татарстан җирләре элек-электән кунакчыл булган, читтән килгәннәрне килмешәк дип санамаган. Киресенчә, үз милләтләренең йөзек кашы булып сакланырга, нәселнәсәбен дәвам итәргә шартлар тудырган.




Өч көн барган фестиваль әйтеп бетергесез хискичерешләр калдырды. Монда һәр студентка үз милләтен күрсәтергә, тәкъдим итәргә мөмкинлек тудырылган иде.

Һәр милләтнең мәдәниятенә юл милли ризыклар аша салына. Беренче көнне безне һәр милләт вәкиле үз аш-суы белән сыйлады. Нинди генә ризыктан авыз итмәдек! Иң беренче булып, Кытай, Корея, Вьетнам вәкилләре янында «гөжләде» халык. Башкортларның кумызлары, бавырсаклары да бик тиз юкка чыкты. Үзбәкләрнең өеп куйган пылаулары да тел йотарлык булды...

Башка халыкларны, аларның холкын, гореф-гадәтләрен, милли йолаларын күбрәк танып-беләсең, гомумән, халыкның күңеленәүтеп керәсең килә икән, биюдәге хәрәкәтләренә күз сал. Фестивальгә җыелучылар да үзләрен төрле милләт биюләрендә сынап карый алды. Бик тә җитез ике хореограф кыз татар халык биюен биергә өйрәтте. Чит ил вәкилләренә генә түгел, безгә, татар студентларына да, бу бию хәрәкәтләрен яңабаштан өйрәнергә туры килде. Көньяк Африка дәүләтеннән килгән Оливерның хәрәкәтләре минекеннән яхшырак чыккалыгы үземне оялтып куйды. Кара, ул Кавказ тау егетләре лезгинканы ничек очынып-очынып бииләр, таҗиклар, азәрбайҗаннар да үз көйләренә бөтерелә. Киң кыргыз, казах далалары егетләре дә горурланып башкардылар биюләрен.

Милләтне танып-белүдә җырлар да мөһим роль уйный. Һәр милләтнең җыры үзенчәлекле. Татар теленә иң якыны, башкортлардан кала, казах, кыргыз, төрекмән телләре икән.

Кичен икенче тормыш башлана иде. Беренче көнне кышны озаттык. Нинди генә фольклор, җырлы-биюле уеннарда катнашмадык! Бүген күп кенә яшьләребез фольклорны күнелсез, ниндидер искелек калдыгы итеп карый. Әмма бу алай түгел. Оештыручылар билгеләп үткәнчә, беренче тапкыр гына оештырыла торган фестивальгә уеннарны әзерләгәндә, алар бар нечкәлекләрне өйрәнгәннәр һәм катнашучыларга элек ничек булса, шулай күрсәтергә тырышканнар. Тик барысын да шаккатыргань этнодискотека булгандыр.

Фестивальнең икенче көнендә вакыйгаларга бай булды. Бирегә килгән милләт вәкилләре үзләрен тәкъдим иттеләр. Теләүчеләр кытай туенда катнашып карады, корея, азәрбайҗан туй йолаларын хозур кылды. Янудләрнең атна башланыр алдыннан үткәрелә торган йолаларында катнашты. Бу көнне эшләргә ярамый икән. Хәтта тырнак аралары шәм яктысында караганнар. Әгәр тузан бөртеге кадәр генә пычрак булса да, ул кешегә тискәре караш ташланган.



Шул көнне «Идел» яшьләр үзәге гүзәле сайланды. Катнашучыкызларның һәркайсы чынлап та гүзәл, ягымлы, үз милләтенең йолдызы иде. Нәтиҗәләргә килгәндә, «Интернациональ «Идел» гүзәле» исемено безнең уку йорты студенты Нәркәс Хәснетдинова лаек булды. Башка номинацияләрдә дә җиңүчеләр билгеләнде.

Өченче көнне бер-беребез белән аралаштык, чарага карата үз фикеребезне җиткердек. Фестиваль һәр кешегә бик күп яңалыклар ачты: яңа дуслар таптык, белемнәребезне арттырдык, милләтләр арасында дуслык күперләрен ныгыттык. Өч көн сизелмичә узып та китте. Ә бит күбесе әле танышып кына өлгергән иде...

Тарих сәхифәләре

# Сөембикә рухын сөендереп

**Гүзәлия ТАРХАНОВА,** Вахитов районының 96 гимназия укытучысы

«Соңгы риваять». М.Маликованың Сөембикә-ханбикә рухына багышлап язылган трагедиясе – әһәмиятле тарихи әсәрләрнең берсе. К.Тинчурин ис. Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистларының бу әсәрне сәхнәдә күрсәтергә алынуы үзе бер егетлеккә тиң, чөнки вакыйгаларны, образларны иҗат иткәндә тарихи дөреслеккә хилафлык китермичә эшләү зур җаваплылык таләп итә. Режиссер Р.Заһидуллинның мондый катлаулы темага мөрәҗәгать итүе беренче мәртәбә генә түгел. Бу юлы да аның иҗат төркеме үз максатына иреште: Казан халкы Сөембикәнең үзен күргәндәй булды, аның фаҗигасен үз йөрәгеннән кичереп утырды.







Спектакль башында ук тамашачы Сөембикә, Кошчак, Колшәриф һәм Нурали Ширин кебек тарихи шәхесләр белән таныштыр. Бер үк диндәге кардәш Кырым ханнарының идарәгә килүеннән курыккан Казан түрәләре Мәскәү патшасы алдында бил бөгүне өстенрәк күрәләр һәм хыянәт юлына басалар. Моның башлангычы тирәндәрәк ята. Татар халкының тарихи бердәмлеген какшатуда Гәүһәршад ханәкә белән Булат Ширин һәм аларның жырын жырлаган Казан морзаларының роле бик зур. Мәскәү патшасының ялагай эте Шаһгалине каткат Казан тәхетенә утыртып уйнаган бу түрәләрнең ахыргы максаты Кырымнан килгән Сафагәрәйне Казан тәхетеннән алып ташлау була. Алар моңа ирешәләр. Ләкин ире Сафагәрәй үтерелгәннән соң, тәхеткә улы Үтәмешгәрәйне утыртып, ул балигъ булганчы, Сөембикә ханбикә идарә итә башлый.

Трагедиядә Нурали Ширин морза (Булат Ширин улы) һәм аның яраннарының Сөембикәгә каршы көрәше, ахыр чиктә Сөембикәне Явыз Иван кулына тапшырып, Шаһгалине кабат Казан тәхетенә кайтарырга тырышу вакыйгалары сурәтләнә.

Сөембикә – татар халкының горурлыгы, аның намусы. Ул гомер бакый гүзәллек үрнәге булып саналган. Минем уйлавымча, бу образны сәхнәдә иҗат итү өчен гаҗәеп осталык кирәк. Режиссерның бу рольне Гүзәл Гайнуллинага тәкъдим итүе бик дөрес булган дип саныйм. Беренчедән, бу артистканың йөз чалымнары портретларда сурәтләнгән Сөембикәне хәтерләтсә, икенчедән, аның сәхнәдә үз-үзен тотышы гүзәл ханбикәнең илаһи буй-сынын, горурлыгын чагылдыра иде сыман.

1550 елда Явыз Иван Казанга чираттагы һөҗүмен башлый. Ханбикә Кремльне саклаучылар арасында үзе дә була. Тарихи язмаларда Сөембикәнең куркусыз характерын сурәтләүче мондый юлларны искә төшерәсе килә: «Ошбу куркыныч вакытларда Казанның гайрәтле, акыллы мәликәсе Сөембикә, крепость өстенә менеп, үзе командалар биреп йөри», – дип язган Зәки Вәлиди аның турында.

1546 елдан бирле Казан ханлыгына хезмәт иткән кырымлы Кошчак углан аның яклаучысы булганда, Сөембикә үзен икеләтә көчле тойган, чөнки бу сугышчыга нык ышанган. Трагедиядә Кошчак образына зур җаваплылык йөкләнгән. Бу рольне башкарган артист Артем Пискунов көчле характерлы Кошчак образын тудыра алды, аның җиңелмәс һәм сатылмас характерын бар яклап та ачып бирде. Дошман баскыннары кулына төшү эпизодында да Артем – Кошчак үз образының батырлыгын күрсәтеп кенә калмады, аңа карата тамашачы күңелендә ихтирам уята алды.

Колшәриф образы безгә Сөембикәне укымышлы, гади халыкка һәрвакыт ярдәм кулы сузучы, Казан халкы өчен утка-суга керергә әзер торучы олы зат итеп күрергә ярдәм итә. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Колшәриф ханбикәнең киңәшчесе булган, аның китапханәсен күз карасыдай саклаган. Үзе дә, Казан диварларын дошманнардан яклап сугышканда, хыянәтче шәкерте кулыннан һәлак булган бу шәхесне татар халкы бүген дә хөрмәтли.

Автор үз трагедиясенә Фатыйма образын юкка гына кертмәгәндер, мөгаен. Сөембикә – дала кызы. Әнә аның сеңлесе, ягъни бу образны иҗат итүче Гөлназ Нәүмәтова, дала җиле сыман ургылып, бөтен тирә-якны шаушуга күмеп, хан сараена килеп керә. Сеңлесе белән сөйләшкәндә, Сөембикә бермәлгә атасы, туганнары калган далага очып китәргә әзер лачынга охшап кала. Әйе, ул да кайчандыр Фатыйма кебек, ат уйнатып, дала буйлап чапкан, тик хәзер ул моны эшли алмый. Ул – ханбикә!

Автор Сөембикәнең аналык хисләрен, аның караучысы Мәрхәбә образы аша ачуга зур игътибар биргән. Атказанган артистка Лилия Мәхмүтова башкарган Мәрхәбә образы да үзенчәлекле. Сөембикәгә тугрылыклы бу хатын – Айбуләкнең (артист Илназ Гыймалетдинов) анасы. Үзен үтерергә теләгән оланга ачуы никадәр зур булса да, Сөембикә аның улын ярлыкый. Ул Мәрхәбәнең баласы өчен өзгәләнүен күрә. Үзе дә ана булган Сөембикә яшь егетне үтертми, киресенчә, аны мәдрәсәсенә шәкерт итеп ала. Автор, беренчедән, Сөембикәнең кешелеклелеген калку планда күрсәтергә теләсә, икенчедән, ул аның акыллы хөкемдар булуына ишарә иткәндер, мөгаен.

Тарихта билгеле булганча, 1551 елның 11 августында Сөембикә һәм улы Үтәмешгәрәй, Кошчакның ике баласы, Ак Мөхәммәд угланның улы мәҗбүри төстә Казаннан Мәскәүгә озатыла. «Мондый вакыйганың охшашын тарих күрмәгән булса да, татар күңеле аны эшләүдән тартынмады», – дип язган тарихчы Һ.Атласи күп еллардан соң. «Соңгы риваять» трагедиясен сәхнәләштергән режиссер безне шул чорларга кайтып уйланырга, татарның яшәешен тагын бер кат күз алдыннан кичерергә, аның киләчәге турында фикер йөртергә чакыра. Тинчурин театрының бу эше, һичшиксез, мактауга лаек, коллективта татарның олысына-кечесенә тәрбия бирү теләге көчле. Сөембикәле халык булуыбызны, тарихыбызны онытмыйк. Киләчәгебезнең нинди булуы үзебезгә бәйле, чөнки тарихны кешеләр тудыра.

Тәүге адымнар

# Һәр чор өчен уртак һөнәр – УКЫТУЧЫ!

**Илмира КАМАЕВА,** татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге

Кечкенәдән үк укытучылы уйнарга ярата идем мин. Өйдәге бөтен кешене утыртып, тактага яза-яза нидер аңлатканымны, тыпыша-тыпыша план язганымны, журнал ясап, аңа билгеләр куйганымны хәтерлим. Ул вакытта укытучы буласы килү теләге бик көчле иде. Хыял үк булгандыр дим мин аны. Шул балачак хыялы быел чынга ашты! Балалар бакчасы – мәктәп – университет һәм кабат МӘКТӘП... Укытучы буларак сынап карадым үземне. Бүген исә Казан шәһәре Авиатөзелеш районының 10нчы гимназиясендә үткән педагогик практика көндәлеген актарып утырам...

*12 нче февраль.* Мәктәпне тәмамлаганга 4 ел һәм мин кабат мәктәптә. Әмма бу юлы мин – укытучы. Гимназия, укучылар һәм, гомумән, бүгенге укыту системасы белән танышу көне... Бүген әле Зөһрә Әхәтовна Сәлахова биргән дәресләрне күзәтеп утырдык. Хәзерге балаларга үзебезчә бәя бирерге тырыштык.

*17 нче февраль.* «Исәнмесез, укучылар! Татар теле дәресен башлыйбыз. Бүгенге дәресне сездә мин укытачакмын». Әлеге җөмләне генә түгел, әйтәсе һәр сүзне дәрес башланыр алдыннан 100 тапкыр кабатлаганмындыр. Беренче дәресемне бирер алдыннан репетиция шулайрак узды. Ничек ерып чыгармын, дигән дәресем бер сулышта үтеп тә китте. Уңышлы үткән дәрестән соң исә, күпме материал туплау, дәрес планын язу, конспектын төзү кебек авырлыклар онытылды. Әле электрон журнал тутыру, дәфтәр тикшерү... Киләчәктә укытучы булырмынмы? Уйлап карарга кирәк!

*28 нче февраль.* Педагогик практиканың чираттагы бер көне. Заман гел үзгәрештә, кешеләр дә үзгәрә, көн саен нинидер яңалык туып тора. Укытучы һөнәре генә һәр чор өчен дә уртак. Ул һәрвакыт кыйблаcына тугры булып, адәм баласын аң-белемле итү юлында армый-талмый хезмәт куя. Мәктәптә укытучы булып эшли алган кеше һәр эштә уңышка ирешә ала торгандыр, дигән фикер калды миндә. Кешелекле, гадел, сабыр кешеләр һөнәре... Мин дә укытучы булмыйм, дип кырт кисмим әлегә.

*5 нче март.* Әле башкалар биргән дәресне карап, әле үзең дәрес биреп, мәктәпкә тәмам ияләшеп беттек. Дәресләребезне үзебезнең төркемдәшләр, методистларыбыз Алсу Дамировна Батталова, Мөслимә Мәгъсүмовна Шәкүрова карап, бәя биреп баралар. Мәктәптә көн саен нинидер кызыклы вакыйга булып тора. Сыйныфтан тыш чаралар оештыру, стена газеталары ясау, музейга сәяхәт... Укытучы һәрвакыт вакыйгалар үзәгендә кайнап яши. Үзе ничә яшьтә булса да, күңеле белән гел сабыйлар яшендәдер ул.

*7 нче март.* Вакытны күпме генә туктатырга тырышсаң да, ул адәм баласының кодрәтеннән килә торган эш түгел. Әле күптән түгел генә башланган практика бүген ахырына да якынлашты. Укыткан укучыларым арасында ничә бала булса, шул кадәр үк характер... Практика вакытында кемдер чаялыгы, тапкырлыгы, кайберсе тәртипсезлеге белән истә калды. Укучыларымның һәрберсе белән уртак тел табуга ирештем. Беренче уңышым шул булгандыр. Зур уңышлар әнә шундый кечкенә генә кисәкләрдән башлана торгандыр. Чын укытучы – бәхетле кеше, чөнки аның кулында бөтен кешелек бәхете. Чын укытучы булырга язсын иде!



● Сәнгать

# Раяз Фасыйхов: «Сәхнәдән көч алам!»

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Һәр һөнәр иясе өчен тупланган нәзари белемне практикада нығыту мөһим. Нәкъ менә шушы максат белән, без, КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студентлары, «Интервью жанры буенча мастер-класс» курсы кысаларында дәресләребезгә танылган шәхесләрне чакырып, алар белән әңгәмә корабыз. Очрашудан соң, интервьюларны төрле гаммәви мәгълүмат чараларында бастырабыз. Узган дәресебезнең кунагы – «Кыр казлары», «Яшьлек иле», «Ярат әле» кебек җырлары, моңлы тавышы белән тамашачы күңелен яулаган яшь җырчы, ТДГПУны тәмамлаган Раяз Фасыйхов иде.





**– Раяз, җырларыгызның һәркайсы үзенчәлекле. Сез аларны ничек сайлыйсыз?**

- Җыр – сүзләр һәм моңның бергә кушылып, аһәң барлыкка китерүе ул. Дустым композитор Оскар Усманов җырда көйнең мөһимрәк булуы хакында бәхәсләшергә ярата. «Битлз», Пол Маккартни, Элтон Джон яисә башка чит ил җырчыларының җырларын тыңлаганда, син бит сүзләрен аңламыйсың, ә мәкиббән китеп тыңлап утырасың», – дигән дәлил китерә. Әмма мин татар җырларының сүзенә өстенлек бирәм. Чөнки җырның бар мәгънәсе – сүз бит инде! Җыр каз тәннәре чыгарырга сәләтле икән, димәк, ул – шәп!

**- Әү үзегезнең җыр язып караганыгыз бармы?**

- Әйе... Тик мин башкаларныкына охшаганрак җыр язып ташлаудан куркам. Шигырь дә язып караганым бар. Билгеле, хисләнеп түгел инде. Ничектер үзеннән-үзе башка килә ул, бигрәк тә төнлә. Үзем ятлаган 20 җырның, башка артистларның репертуарындагы, классик җырларның текстлары баш миендә сакланып, күрәсең, бергә бутала да шигырь килеп чыга. Көйләр белән дә шулайрак. Шуңа күрә мин җыр язам, дип азапланмыйм. Чөнки моның өчен профессионаллар бар!

**- Сез ничек илһамланасыз? Күңел төшенкелеге булган чакта бу халәттән ничек котыласыз?**

- Дөресен генә әйткәндә, озак вакыт сәхнәгә чыкмый торсам, депрессиягә бирeләм. Мин сәхнәдән көч алам. Һәр иҗат кичәсенә хас булган хисчәнлек миңа да хас. Шуңа илһамлану төрлечә булырга мөмкин. Кайвакыт моның өчен кем беләндер танышу, күрешеп аралашу да җитә. Балалар, әти-әнием, якыннарым да – илһам чыганагым. Шәһәр шаукымыннан арып-талган чакта, мин авылга кайтып китү ягын карыйм – үткәннәремә, балачагыма кайтам... Табигатькә чыгып китү җаңга ял, илһам өсти.

**- Фанатларыгыз белән ничек аралашасыз?**

- Әлбәттә, күбрәк интернет аша.

**- Сәхнәдәге һәм тормыштагы Раяз Фасыйхов аерымы?**

- Аерыла һәм ничек кенә әле. Дөрес, мин җырларымның һәркайсын үзем аша кичереп, хисләнеп җырлыйм. Әмма тормышта мин бөтенләй башка: андый хисле түгел, реалист кеше. Һәрвакыт туры сүзле, кайвакыт кырыс та. Мәхәббәттә мин җырларымдагыча романтик булырга тырышам. Әмма, ни кызганыч, һәрвакыт килеп чыкмый шул.

**- Сәхнә образы өстендә кемнәр эшли, костюмнарны ничек сайлыйсыз?**

- Моның белән профессионаллар – имиджмейкерлар шөгыльләнә. Бүген, Аллага шөкер, элеккеге заманнарда популяр булган «космик» костюмнар кию модасы бетте. Хәзер гадилектә – матурлык. Шулай да җырчылар сәхнәгә көндәлек кием белән чыга, дип тә әйтеп булмый. Өс киеме күп очракта җырланасы җыр һәм тудырылган образга туры китереп сайлана. Бу өлкәдә тормыш иптәшем Люция дә ярдәм итә.

**- Сезнең белән интервьюлар күп чыкты бит инде. Аларда сез җырчы Салаватны хөрмәт итүегез хакында әйтәсез. Ә менә Салаватның «Журналистларны күрә алмыйм», – дигән сүзләренә ничек карыйсыз?**

- Миңа калса, аның бу сүзләре бер пиар адымы гына. Чөнки бүгенгә кара пиарны әле берәү дә кире какмый. Журналистларга карата үземнең мөнәсәбәткә килгәндә, сез – безне тамашачылар белән тагын бер кат очраштыра торган күпер. Шуңа аралашырга яратам, диалогка һәрвакыт әзер. Әмма шәхси тормышка кагылган гайбәтләр таратучы журналистларга каршымын.

● Тәңгә - мунча, җаңга - юк

# Студентка урын кирәк. Машинасына!

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Аның кесәсендә акча аз, юньләп ашамаган, вакыты да юк диярлек. Бу кем? Әлеге табышмакка әлек «студент» дип җавап биреп була иде. Хәзер исә «студент» төшенчәсе шактый үзгәрде. Вуз укучылары арасында күп кеше кәттә, бай киенә һәм машинада йөри.

Унбиш ел элек югары уку йортын тәмамлаган абыем әйтүенчә, алар укыганда машиналы студентлар бик аз булган. Булганнарының да күбесе – бишенче курста укучылар һәм, белем алу белән бергә, кайда да булса эшләүчеләр. Хәзер хәлләр бөтенләй башка: «тимер ат»та җилдерүчеләрнең исәбе юк. Шуңа күрә уку йортлары каршында машина куярга урын җитми.

Мондый хәлне башкаланың бөтен вузлары янәшәсендә күреп була. КФУ студентлары элек үз машиналарын Кремль урамында, «Тукталырга ярамый» дигән билге янында да калдыра иде. Хәзер үзәк урамнарда машиналар калдыруга каршы канун чыкты.

КДЭУ каршында урнашкан «Автомобиль парковкасы»нда да буш урын табу бик кыен. Шуңа күрә бу вуз студентларына үз машиналарын югары уку йорты янында урнашкан сәүдә үзәкләре янында калдырырга туры килә. КДТУ һәм КДАУда укучы студентларның хәлләре бөтенләй мөшкел. Чөнки бу вузлар янында, гомумән, «парковка» урыннары юк.

Автомобильнең имин тору мәсьәләсе бөтен машиналы студентларны да борчый торгандыр. Алар «парковка» өчен акча түләргә дә әзер. Машиналарына гына тимәсеннәр! КФУның юридик факультет студенты Рамил әнә шундыйлардан. Аның фикеренчә, аена 400-600 сумлык «парковка» төзесәләр, студентлар машиналарын шунда калдырыр иде.

Сүз дә юк, хәзерге вакытта машинасыз авыр. КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студенты Динар да шулай уйлый. «Университет корпуслары шәһәрнең төрле җирендә урнашкан. Кайбер вакытта көненә әллә ничә урында булырга туры килә. Автобуста йөрсәң, акча да күп китә, дәрескә дә соңга каласың. Ә машина бөтен җиргә өлгертә», – ди ул. Икътисад һәм финанс институтында укучы Айгөл исә «тимер ат»ка ерак яшәгәнгә күрә утырган. Авиатөзелеш районында яшәүче бу кыз университетка кадәр автобуста килендә сәгать ярым килә.

Минем дусларым арасында да укуга машинада йөрүче студентлар күп. Аларның күпчелегенә «тимер ат»ларын әти-әниләре бүләк иткән. Автомобильләрне дә теләсә нинди түгел, ә иномаркалар! Шуннысы кызык, университет янындагы «парковка»ларда студент машиналары вузда эшләүчеләрнекенә караганда да күбрәк. Якынча 3-4 миллионлык машинага утырган кызларның, «дустын» кая куярга белмичә, аптырап торганнарын күргәнем бар. Шулай итеп алар укуга соңга кала яки бөтенләй парларны «тозлый». Нәтиҗәдә, машина кайбер студентларга укырга комачаулый булып чыгара. Аңа өстәп, югары уку йортларында эшләүчеләрнең «тимер ат»лары арзанлырак та. Кызыклы каршылык: укытучылар үзләренә ошаган машина ала алмый, ә аларның шәкертләре, әни-әнисе җилкәсенә утырып, «джип»та җилдерә. Димәк, «тимер ат»ны «ашату», ара-тирә «дәвалап тору» (ә бу бит бик кыйммәт!) да ата-ана җилкәсендә, дигән сүз! Аптырарлык түгел, хәтта мәктәптә укучылар дә сыйныфта укучылар да дәрескә үз машинасы белән килә. Дәрескә соңга калып керсәләр дә, аларга кисәтү ясау юк, ул бит бик изге эш белән шөгыльләнгән – машинасына урын эзләгән.





*Влад Михневский фотолары*

● Игътибар! Конкурс!



«Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?! Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны...» – дип язып калдырган бөек Тукаебыз. Сезнең күңелдә дә шигырь уты янамы? Алайса, үзегез язган шигырьләрне Казан университетының 210 еллыгына багышлап уздырыла торган шигырь конкурсына җибәрегез!

Бәйгегә старт Халыкара туган тел көне, ягъни 21 февральдә бирелде. Анда университетыбыз студентлары һәм хезмәткәрләре дә катнаша ала. Конкурс ике этапта уздырыла. «КФУ студентлары шигырьләре», «КФУ хезмәткәрләре шигырьләре» номинацияләре буенча рус һәм татар телләрендә материаллар кабул ителә. Татар телендәге әсәрләр 2014 елның 15 апреле, рус телендәгеләре исә 2014 елның 25 маена кадәр кабул ителә. Конкурска бер кешедән 5 эш тәкъдим ителергә мөмкин. Материалларны КФУның Матбугат үзәге электрон почтасы - ***pressa@kpfu.ru*** га җибәрергә кирәк. 1, 2, 3 урынга лаек булучыларны диплом һәм кыйммәтле бүләкләр көтә. Иң яхшы дип табылган эшләр университет сайтында басылачак. Аларны шулай ук җыентык итеп бастыру да планлаштырыла.

DARELFØNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.